**Казан шәһәре Башкарма комитетының**
**2025 елның 24 февралендәге 440 номерлы карары**

**«Айда» нәфис фильмын төшерү чорында**
**транспорт чараларын куеп торуны һәм**
**аларның хәрәкәтен чикләү турында**

«Айда» нәфис фильмын төшерү чорында юл хәрәкәте иминлеген тәэмин итү максатыннан, 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы федераль закон, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2013 елның 31 маендагы 372 номерлы «Төбәк әһәмиятендәге яки муниципальара, җирле әһәмияттәге автомобиль юлларында транспорт чаралары хәрәкәтен вакытлыча чикләүне яисә вакытлыча туктатуны гамәлгә ашыру тәртибен раслау турында»гы карары нигезендә:

1. **Карар бирәм**:

1.1. кирәк булганда 2025 елның 25 февралендә 00.00 сәгатьтән 20.00 сәгатькә кадәр Казан шәһәре урам-юл челтәренең түбәндәге участокларында транспорт чараларын куеп торуны һәм аларның хәрәкәтен чикләүне кертергә:

- Кремль урамы, Университет урамыннан Беренче Май мәйданына кадәрге участокта;
- Чернышевский урамы, Профсоюз урамыннан Дзержинский урамына кадәрге участокта;
- Муса Җәлил урамы, Профсоюз урамыннан Дзержинский урамына кадәрге участокта;
- Кави Нәҗми урамы, Профсоюз урамыннан Дзержинский урамына кадәрге участокта;
- Астрономия урамы, Профсоюз урамыннан Кремль урамына кадәрге участокта;
- Лобачевский урамы, Кремль урамыннан Дзержинский урамына кадәрге участокта;

- Университет урамы, Профсоюз урамыннан Кремль урамына кадәрге участокта;

- Профессор Нужин урамы, Пушкин урамыннан Кремль урамына кадәрге участокта;

1.2. Казан шәһәре Башкарма комитетының Транспорт комитетына (А.В.Сидоров):

1.2.1. әлеге карарга кушымта нигезендә вакытлы юл билгеләрен урнаштыру һәм гамәлдәге юл билгеләрен каплау буенча чаралар оештырырга;

1.2.2. транспорт чаралары хәрәкәтен вакытлыча чикләү турында мәгълүматны Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгының Интернет челтәрендә Татарстан Республикасының «Татарстан Республикасы рәсми порталы» дәүләт мәгълүмат системасы составына керә торган рәсми сайтында урнаштырырга;

1.3. Казан шәһәре Башкарма комитетының Тышкы төзекләндерү комитетына (И.И.Сәлахетдинов) Казан шәһәре Башкарма комитетының Вахитов һәм Идел буе районнары администрациясе белән берлектә (А.И.Салихов) юлларны йөк техникасы яки таранга каршы блоклар белән ябу эшен оештырырга;

1.4. әлеге карарны «Муниципаль хокукый актлар һәм башка рәсми мәгълүмат» челтәр басмасында (www.docskzn.ru) бастырырга, Казан шәһәре җирле үзидарә органнарының рәсми порталында (www.kzn.ru) һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

**2. Тәкъдим итәм:**

2.1. Россия Федерациясе Эчке эшләр министрлыгының Казан шәһәре буенча идарәсенә (Н.Д.Закиров) әлеге карар нигезендә Казан шәһәре урам-юл челтәренең югарыда күрсәтелгән участокларында юл хәрәкәте иминлеген саклауны һәм оештыру-көйләү гамәлләрен башкаруны контрольдә тотуны тәэмин итәргә;

2.2. Казан шәһәре Думасы аппаратының Мәгълүмат-аналитика идарәсенә (В.А.Казанцев) урам-юл челтәренең күрсәтелгән участокларында транспорт чаралары хәрәкәтен һәм аларны куеп торуны вакытлыча чикләүне кертү турында массакүләм мәгълүмат чаралары аша хәбәр итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Казан шәһәре Башкарма комитеты Җитәкчесе урынбасары И.С.Шакировка **йөкләргә**.

**Җитәкче** **Р.Г.Гафаров**